КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 29 март г.Казань № 238

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгълүмат технологияләре һәм робототехника өлкәсендә семинарлар, конференцияләр, форумнар, олимпиадалар, интеллектуаль конкурслар һәм белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен бүтән чаралар оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә (каплауга) коммерциячел булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 17 июль, 499 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгълүмат технологияләре һәм робототехника өлкәсендә семинарлар, конференцияләр, форумнар, олимпиадалар, интеллектуаль конкурслар һәм белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен бүтән чаралар оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә (каплауга) коммерциячел булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 17 июль, 499 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 5 март, 130 нчы; 2018 ел, 21 сентябрь, 811 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәгълүмат технологияләре, цифрлы икътисад һәм (яки) робототехника өлкәсендә семинарлар, конференцияләр, форумнар, олимпиадалар, интеллектуаль конкурслар һәм башка чаралар оештыруга һәм үткәрүгә бәйле, шулай ук әлеге чараларда Татарстан Республикасы командалары катнашуын тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»;

1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу карарга теркәлгән Мәгълүмат технологияләре, цифрлы икътисад һәм (яки) робототехника өлкәсендә семинарлар, конференцияләр, форумнар, олимпиадалар, интеллектуаль конкурслар һәм башка чаралар оештыруга һәм үткәрүгә бәйле, шулай ук әлеге чараларда Татарстан Республикасы командалары катнашуын тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.»;

әлеге карар белән расланган Мәгълүмат технологияләре һәм робототехника өлкәсендә семинарлар, конференцияләр, форумнар, олимпиадалар, интеллектуаль конкурслар һәм белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен бүтән чаралар оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә (каплауга) коммерциячел булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәгълүмат технологияләре, цифрлы икътисад һәм (яки) робототехника өлкәсендә семинарлар, конференцияләр, форумнар, олимпиадалар, интеллектуаль конкурслар һәм башка чаралар оештыруга һәм үткәрүгә бәйле, шулай ук әлеге чараларда Татарстан Республикасы командалары катнашуын тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе»;

1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм мәгълүмат технологияләре, цифрлы икътисад һәм (яки) робототехника өлкәсендә семинарлар, конференцияләр, форумнар, олимпиадалар, интеллектуаль конкурслар һәм башка чаралар оештыруга һәм үткәрүгә бәйле, шулай ук әлеге чараларда Татарстан Республикасы командалары катнашуын тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү механизмын билгеләү.»;

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Субсидияләр мәгълүмат технологияләре, цифрлы икътисад һәм (яки) робототехника өлкәсендә семинарлар, конференцияләр, форумнар, олимпиадалар, интеллектуаль конкурслар һәм башка чаралар оештыруга һәм үткәрүгә бәйле, шулай ук әлеге чараларда Татарстан Республикасы командалары катнашуын тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү (каплау) максатларында бирелә.»;

4 нче пунктның икенче абзацын төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле $4^1$ нче пункт өстәргә:

«4[1]. Субсидия алу өчен коммерциягә карамаган оешмаларны сайлап алу критерийлары:

коммерциягә карамаган оешма эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыру;

коммерциягә карамаган оешманың устав эшчәнлеген мәгълүмат технологияләрен, цифрлы икътисадны һәм (яки) робототехниканы үстерүгә юнәлдерү.»;

6 нче пунктта «эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә» сүзләрен « эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә» сүзләренә алыштырырга;

7 нче пунктның өченче абзацында «өч көн эчендә» сүзләрен «биш көн эчендә» сүзләренә алыштырырга;

9 нчы пунктта «бер көн эчендә» сүзләрен «эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә» сүзләренә алыштырырга;

18 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Субсидия алучы тарафыннан бу Тәртипнең 14 нче һәм 17 нче пунктлары белән билгеләнгән субсидияне ирекле рәвештә кире кайтару вакыты бозылган очракта, Министрлык әлеге вакыт чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны закон белән билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри түләттерү буенча чаралар күрә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин